ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2023 с.Старое Дрожжаное № 43

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 1 декабрендәге 48 номерлы (2019 елның 14 февралендәге 11 номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 32 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**7.3 пунктта** «электрон почта адресын» сүзләрен «шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификаторын) файдалана, «аңа» сүзен «аның» сүзе белән алыштырырга;

**11.4 пунктта** «вазыйфаи затка электрон документ формасында,» сүзләреннән соң «яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы М.Р. Гафаров